ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.05.2022 г. Казань № 209/2022

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым боерыкларын үз көчен югалткан дип тану турында**

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының хокукый актларын актуальләштерү максатларында
б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип таныргa:

«Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыруга биремнәрне һәм аларның эчтәлеген һәм газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы, тимер юл белән ташулар өлкәсендә, транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда хезмәтләр күрсәтү һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану буенча хезмәтләр күрсәтү өлкәләрендә эшчәнлек башкаручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә үткәрелгән контрольлек чаралары нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты вазыйфаи затлары тарафыннан рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2019 елның 19 мартындагы 35 номерлы;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 19 мартындагы 35 номерлы боерыгы белән расланган Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыруга биремнәрне һәм аларның эчтәлеген һәм газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы, тимер юл белән ташулар өлкәсендә, транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда хезмәтләр күрсәтү һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану буенча хезмәтләр күрсәтү өлкәләрендә эшчәнлек башкаручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре

оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә үткәрелгән контрольлек чаралары нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты вазыйфаи затлары тарафыннан рәсмиләштерү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 22 гыйнварындагы 8 номерлы.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина